СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

30.09.2016 с. Татарское Бурнашево № 13-61

Бурнаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, 28.07.2016 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты нигезендә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», Бурнаш авыл җирлеге Уставының 11 ст., Бурнаш авыл җирлеге Советының 20.09.2016 ел, № 12-58 «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары, «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» Бурнаш авыл җирлеге башлыгының 20.09. 2016 ел № 18 карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Бурнаш авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2016 елның 20 ноябренә җирле референдумны билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Бурнаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән акчалар белән килешәсезме:

- Бурнаш авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә контейнер мәйданчыклары төзү;

Татар Бурнашы авылы: контейнер мәйданчыклары төзү-5 данә, контейнерлар сатып алу-15 данә;

Каинки авылында : контейнер мәйданчыклары төзү-2 шт, контейнерлар алу-6 шт;

Гаврилково авылы: контейнер мәйданчыклары төзелеше-1 данә, контейнерлар сатып алу-3 шт;

Юматово авылы: контейнер мәйданчыклары төзелеше-2 данә, контейнерлар сатып алу-6 данә;

ӘЙЕ ЮК.

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында бастырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин